**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О внесении изменений в статьи 20 и 23 Закона Республики Татарстан «О музеях и музейном деле в Республике Татарстан»**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
18 марта 2019 года

**Статья 1**

Внести в Закон Республики Татарстан от 14 октября 2010 года № 69-ЗРТ «О музеях и музейном деле в Республике Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2010, № 10 (II часть); 2011, № 10 (I часть); 2015, № 10 (I часть); 2016, № 6 (I часть); Собрание законодательства Республики Татарстан, 2017, № 4; 2018, № 78 (часть I) следующие изменения:

1) в части 1 статьи 20 слово «законодательством» заменить словами «Федеральным законом»;

2) в статье 23:

а) часть 1 дополнить предложением следующего содержания: «Территория музея-заповедника может включать в себя водный объект, участок береговой полосы водного объекта, либо территория музея-заповедника может примыкать к участку береговой полосы расположенного вне границ территории музея-заповедника водного объекта.»;

б) часть 5 изложить в следующей редакции:

«5. Правила посещения музея-заповедника устанавливаются музеем-заповедником и доводятся до сведения граждан путем размещения на официальном сайте музея-заповедника в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет», в зоне организации приема посетителей музея-заповедника, в иных доступных для них местах на территории музея-заповедника.»;

в) дополнить частью $5^1$ следующего содержания:

«$5^1$. Правила посещения музея-заповедника включают в себя в том числе:

1) особенности использования расположенных на территории музея-заповедника водного объекта, участка береговой полосы водного объекта, а также расположенного вне границ территории музея-заповедника водного объекта, к участку береговой полосы которого примыкает территория музея-заповедника;

2) особенности доступа к расположенным на территории музея-заповедника водному объекту, участку береговой полосы водного объекта, а также к участку береговой полосы, к которому примыкает территория музея-заповедника, водного объекта, расположенного вне границ территории музея-заповедника;

3) правила поведения посетителей музея-заповедника на территории музея-заповедника и на объектах, которые на ней расположены;

4) правила поведения граждан на примыкающем к территории музея-заповедника участке береговой полосы расположенного вне границ территории музея-заповедника водного объекта;

5) иную необходимую для посетителей музея-заповедника информацию.»;

г) дополнить частью $6^1$ следующего содержания:

«$6^1$. Граждане, постоянно проживающие на территории музея-заповедника, в границах его территории имеют право на осуществление деятельности, направленной на обеспечение своей жизнедеятельности, в том числе деятельности, требующей их свободного доступа к расположенному на территории музея-заповедника водному объекту, участку береговой полосы такого водного объекта, а также к участку береговой полосы, к которому примыкает территория музея-заповедника, водного объекта, расположенного вне границ территории музея-заповедника. В границах территории музея-заповедника допускается деятельность постоянно проживающих на его территории граждан, направленная на сохранение исторически сложившихся видов деятельности, осуществляемых сложившимися, характерными для данной территории способами, в том числе с использованием водных объектов, их частей.».

**Статья 2**

Настоящий Закон вступает в силу через 10 дней после дня его официального опубликования.

Президент
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
05 апреля 2019 года
№ 28-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**“Татарстан Республикасында музейлар һәм музей эше турында” Татарстан Республикасы Законының 20 һәм 23 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2019 елның 18 мартында
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасында музейлар һәм музей эше турында” 2010 елның 14 октябрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 10 (I өлеш); 2015, № 10 (I өлеш); 2016, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 4; 2018, № 78 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 20 статьяның 1 өлешендә “законнарда” сүзен “Федераль законда” сүзләренә алмаштырырга;

2) 23 статьяда:

а) 1 өлешкә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: “Музей-тыюлык территориясенә су объекты, су объектының яр буе полосасы кишәрлеге керергә мөмкин, йә музей-тыюлык территориясе аның территориясе чикләреннән читтә урнашкан су объектының яр буе полосасы кишәрлегенә тоташкан булырга мөмкин.”;

б) 5 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“5. Музей-тыюлыкта булу кагыйдәләре музей-тыюлык тарафыннан билгеләнә һәм гражданнарга “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә музей-тыюлыкның рәсми сайтына, музей-тыюлыкка килүчеләрне кабул итүне оештыру зонасында, музей-тыюлык территориясендә алар күрә алырлык башка җирләрдә урнаштыру юлы белән җиткерелә.”;

в) түбәндәге эчтәлекле $5^1$ өлеш өстәргә:

“$5^1$. Музей-тыюлыкта булу кагыйдәләренә шул исәптән түбәндәгеләр керә:

1) музей-тыюлык территориясендә урнашкан су объектыннан, су объектының яр буе полосасы кишәрлегеннән, шулай ук музей-тыюлык территориясе

чикләреннән читтә урнашкан, яр буе полосасы кишәрлегенә музей-тыюлык территориясе тоташкан су объектыннан файдалану үзенчәлекләре;

2) музей-тыюлык территориясендә урнашкан су объектына, су объектының яр буе полосасы кишәрлегенә, шулай ук музей-тыюлык территориясе чикләреннән читтә урнашкан су объектының музей-тыюлык территориясенә тоташкан яр буе полосасы кишәрлегенә керә алу үзенчәлекләре;

3) музей-тыюлык территориясендә һәм анда урнашкан объектларда музей-тыюлыкка килүчеләрнең үз-үзләрен тоту кагыйдәләре;

4) музей-тыюлык территориясе чикләреннән читтә урнашкан су объектының музей-тыюлык территориясенә тоташкан яр буе полосасы кишәрлегендә гражданнарның үз-үзләрен тоту кагыйдәләре;

5) музей-тыюлыкка килүчеләр өчен кирәкле башка мәгълүмат.”;

г) түбәндәге эчтәлекле $6^{1}$ өлеш өстәргә:

“$6^{1}$. Музей-тыюлык территориясендә даими яшәүче гражданнар аның территориясе чикләрендә үз яшәешләрен тәэмин итә торган эшчәнлекне, шул исәптән музей-тыюлык территориясендә урнашкан су объектына, су объектының яр буе полосасы кишәрлегенә, шулай ук музей-тыюлык территориясе чикләреннән читтә урнашкан су объектының музей-тыюлык территориясенә тоташкан яр буе полосасы кишәрлегенә аларның иркле керә алуын таләп итә торган эшчәнлекне гамәлгә ашырырга хокуклы. Музей-тыюлык территориясе чикләрендә аның территориясендә даими яшәүче гражданнарның әлеге территория өчен хас булган ысуллар белән башкарыла торган, шул исәптән су объектларыннан, аларның өлешләреннән файдаланып, электән билгеле булган эшчәнлек төрләрен саклап калуга юнәлдерелгән эшчәнлеге рөхсәт ителә.”.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН * ГОМУМИ БҮЛЕК ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2019 ел, 05 апрель
№ 28-ТРЗ